**Конспект урока родного (татарского) языка по теме "Туган көндә" текстындагы яңа лексика**

Саттарова Г.Я.,
учитель МАОУ "Надежда"

**Максат**:

1. "Туган көндә" тексты белән танышу, күнегүләр системасы аша үзләштерү.
2. Укучыларның тыңлап, аңлап сөйләм күнекмәләрен, аралашу күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтләренен, мөстәкыйльлекләрен, иҗади активлыкларын үстерү, укучыларның үз фикерләрен тиз һәм төгәл әйтә белүләренә ирешү, шулардан чыгып нәтиҗә ясый белүләренә ирешү;
3. Сыйныфта дустанә мөнәсәбәт булдыру; якын кешеләргә мәхәббәт һәм хөрмәт тәрбияләү.

**УУЭ**

**Регулятив:**

- укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү;
- кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- билгеләнгән критерийларга таянып, эш сыйфатына бәя бирә белү.

**Танып белү:**

-укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү;
-төшенчәгә якын килү өчен нәтиҗә ясау.

**Коммуникатив:**

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңлый һәм аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- бердәм эшчәнлектә уртак нәтиҗәгә килү;
- парлап һәм төркемдә эшли белү.

**Шәхси:**

- ярдәмчеллек, башка кешеләргә карата кайгыртучан булу.

**Җиһазлау:**

- мультимедиа экран, компьютер, ситуатив биремле карточкалар, презентация.

**Кирәкле материаллар:**

- ак А4 бите, карандаш, җилем, кайчы.

Укучылар төркемнәрдә эшлиләр. Традицион булмаган утыру *(йөзгә-йөз, җилкәгә-җилкә)*

**Дәреснең тибы:**яңа белем-күнекмәләр булдыру.

**Предметарабәйләнеш:** сынлы сәнгать.

**Дәрес барышы:**

**I. Оештыру өлеше.Уңай психологик хәләт тудыру.**

1.— Исәнмесез,укучылар! Хәерле көннәр сезгә. Зиһен һәм тел ачкычлары телимен һәммәгезгә!

- Исәнмесез,балалар!
- Исәнмесез, хәерле көн!

Матур үтсен көнебез!
Көләч булсын йөзебез!
Булыйк һәрчак әдәпле,

Отыйк матур гадәтне.
Дөрес, матур утырыйк,
Тырышып җавап бирик.

2. Дежур укучы белән әңгәмә:

- Бүген сыйныфта кем дежур?
- Бүген сыйныфта мин дежур.
- Бүген ничәнче число?
- Бүген 6 нчы февраль.
- Атнаның нинди көне?
- Дүшәмбе.
- Бүген көн нинди?
- Бүген көн салкын, кояшлы, җил исә.
- Сыйныфта кемнәр юк?
- Сыйныфта барысы да бар.

II. Белемнәрне актуальләштерү. **Укучыларның уку эшчәнлеген мотивлаштыру.**

1.“ө” авазына фонетик күнегү. Слайдта түбәндәге сүзләр: өстәл, сөт, гөбәдия, өчпочмак, көн, төн, “өч”ле, сөйләшә, йөри, йөз, дөрес, өй, өй эше.

Укытучы укый, балалар укытучы артыннан кабатлый. Сүзтезмәләр, җөмләләр төзү.

2.Ишетеп аңлау күнекмәсе (аудирование).

Диалог тыңлыйк: катнашалар: Ләйсән белән Марат.

*Слайдта сораулар:*

- Укучылар, дәфтәрләрне ачып, числоны язып куйыйк. Ишеткән диалог буенча тест чишәбез.

1. ... Ләйсәннең туган көне.
   а) бүген;
   б) иртәгә;
   в) кичә.
2. Ләйсән туган көнен ... .
   а) ярата;
   б) яратмый;
   в) бик көтә.
3. Ләйсәннәр туган көнендә .... баралар.
   а) кафега;
   б) кунакханәгә;
   в) ресторанга..
4. Пиццаны..... яратмый
   а)Илнур;
   б)Ләйсән;
   в) Марат.
5. Ләйсәннең туган көненә әтисе белән әнисе ... бүләк иткәннәр.
   а) сәгать;
   б) күлмәк;
   в) итәк.
6. Ләйсәннең туган көне .... урамдагы ресторанда үтә .
   а) зәңгәр;
   б) кызыл;

в) яшел.

- Дәфтәрләрләрегез белән алышыгыз һәм иптәшегезнең эшен карандаш белән тикшерегез. *(слайдта җаваплар).* Әгәр алты сорауга да җавап дөрес булса, “бишле” билгесе куегыз, “дүртле” билгесе биш сорауга җавап дөрес булса куела. Өч-дүрт сорауга дөрес җавап биргән булса - “өчле”, бер-ике сорауга – “икеле”.

3.*Видео. Мультьфильм “Чебурашка“ дан өзек карау.*

Димәк, дәрестә нинди бәйрәм турында сүз барыр?

- Туган көн бәйрәме.
- Әйе, без бүген туган көн турында сөйләшербез. Туган көндә нишлиләр?
- Өстәл әзерлиләр, уйныйлар, җырлыйлар, бииләр, котлыйлар.

4.Уку мәсьәләсен кую.

- Укучылар, бүген без “Туган көндә” дип аталган хикәя укырбыз, Фәридә исемле кыз белән танышырбыз. Ул кыз сезгә ошармы? Сез аңа нинди киңәшләр бирерсез икән?

- Бу хикәянең авторы Резидә Вәлиева. Биографиясе белән танышу. (Дәфтәргә язу).

Р.В. 1930елның 1 нче маенда Башкортстанда авылда укытучылар гаиләсендә туа. Казан дәүләт университетын тәмамлый. 30 елдан артык Татар китап нәшриятында балалар әдәбияты бүлеге мөхәррире (редактором) булып эшли. Бүгенге көндә аның 40тан артык шигырьләр, поэмалар, әкиятләр, табышмаклар җыентыгы бар. Аның иҗатында табигатькә, туган якка мәхәббәт, саф хисләр.

Беренче җыентыгы 1960 елда чыга, исеме- “Минем дусларым”. Аннары “Нәниләргә бүләк”, “Язгы сулар”, “Дәү әнигә барабыз” һәм башка китаплары. Р.В. – күпсанлы җырлар авторы. Ул шулай ук (также) рус балалар поэзиясен татар теленә тәрҗемә итә.

**III. Яңа белем-күнекмәләр булдыру.**

**Уку мәсьәләсен чишү.**

**1.Сүзлек эше.**

Чыкмасын әле – пусть не выходит

Аннан соң - потом

Искиткеч –удивительный

Бераз –немного,некоторое время

Борчулы –расстроенный

Уздырмыйбыз – небудем проводить

**2.Әсәрне укып чыгу.**

**3.Кире информация.**

**Укытучы:**

- Укучылар, сезгә хикәя ошадымы?
- Хикәя нәрсә турында?
- Әсәрдә кемнәр катнаша? ( Фәридә, аның әнисе, әби)
- Фәридә әнисе белән нинди бәйрәм үткәрергә әзерләнә?
- Фәриденең әнисе нәрсә пешергән?
- Бәйрәм нинди булырга тиеш иде?
- Ни өчен бәйрәм булмый?

-Хикәя сезнең күңелдә нинди хисләр уятты?

-Фәриденең әнисен нинди дип әйтеп була? (Тырыш, уңган)

Тактага әнисенә хас сыйфатларыны тезеп чыгалар

Әни - эшчән, тырыш, кешелекле, сабыр, мәрхәмәтле, өлкәннәрне хөрмәт итә, игътибарлы , уңган, тәрбияле.
-Аны кем тәрбияләп үстергән? (Аны Фәридәнең әбисе тәрбияләп үстергән.)
-Фәридә әнисенә нәрсә дип керә?
-Әнисе ни өчен үзгәреп киткән? (Чөнки ул кызыннан андый сүзләрне ишетергә теләмәгән)
-Әсәрнең төп герое кем? (Фәридә)

- Фәриданең әбисе турында әйткән сүзләрен табып укы.
- Ни өчен Фәридәнең әнисе борчыла?
-Фәридәнең әнисе үз әнисен кимсеттергәнме?
-Ул кемне ярата?
- Фәридә сезгә ошадымы?(Әңгәмә үткәрелә)
Төркемнәрдә эш- образларга кыскача характеристика бирү . Кластер төзү
1 төркем-Фәридә, 2 төркем- әнисе, 3 төркем –әбисе, 4 төркем - әбигә булышу.
**Үзбәя.**
3**) Рәсем буенча эш.**
-Рәсемне карагыз.
- Фәридә нинди? (Ул яшь, кечкенә, матур, ләкин усал)
- Фәридәнең әбисе нинди? (Әбисе карт, яхшы)
- Фәридә гел шулай кечкенә, матур булып торырмы? (Юк.)
- Ни өчен?
- Фәридәнең әбисе элек нинди булган дип уйлыйсыз?
- Син Фәридәнең нинди булып үсүен телисең?
- Әсәрне ничә өлешкә бүлеп була? (ике)
- Беренче өлештә өйдә һәммәсенең кәефе нинди була? (күңелле )
- Икенче өлешендә нинди кәеф? (кәеф төшкән,борчылу)
- Ни өчен?(чөнки Фәридә әбисен туган көндә күрәсе килми)
**Шатлык —— борчылу(тактада)**
— Бу каршылык Фәридәнең үз әбисенең тышкы матурлыгын гына күрү аркасында килеп чыга. Димәк, автор нәрсә әйтергә тели? (**Кешенең тышкы матурлыгына гына түгел, эшке матурлыкны күрә белергә кирәклеген әйтә**).
— Укучылар, Фәридә хәзер матур булып күренәме?
— Ни өчен?
4.Физ. минут.
**Укытучы**: Ә хәзер, әйдәгез, Фәридәне котлап, “Ак калач” уенын уйнап, ял итеп алыйк әле.

**IV. Белем һәм күнекмәләрне ныгыту**

**1.Әбиләр турында сөйләү.**
-Сезнең барыгызның да әбиләре бар. Сез аларны яратасызмы?
Әбиләрегез турында нинди җылы сүзләр әйтә аласыз? Без сезнең белән әбиләргә багышлап бик күп эшләр эшләдек. Әйдәгез үзегезнең иҗади эшләрегез белән таныштырып китегез.
Безнең Камил әбисе турында шигырь чыгарган.
Динара әбисе турында презентация ясаган.
Камилла газета чыгарган.

Юра әбисенең портретын ясаган.
Артем әбисенең нинди тәмле ашлар пешергәне турында сөйләп китәр.
Ангелина әбисенең кул эшләренең күргәзмәсен оештырган.
Алмаз әбисе турында сочинение язган.
Саша әбиләр турында шигырьләр җыентыгы ясаган.
Сезнең әбиләрегезне яратуыгыз аларга игътибарыгыз, хөрмәтегез чиксез булуы мине сөендерә.
Камил шигырь сөйли. “Әбием минем”.

**2.Әбиләр турында җыр тыңлау. Музыка.**
**Үзбәя.**
**3. Карточка белән эш.**

__**Укытучы**__**:** Текстны укып чыгыгыз биремнәрне эшләгез.

***2) Прочитайте текст. Определите, какие из приведённых утверждений А1-А8 соответствуют содержанию текста (1 – дөрес), какие не соответствуют (2 – дөрес түгел).***

А1. Бүген Фәридәнең туган көне.
1) туры килә, 2) туры килми,
А2. Әнисе иртән бәлеш пешергән..
1) туры килә 2) туры килми
А3. Тиздән аның дус малайлары да килеп җитәр.
1) туры килә 2) туры килми
А4. Әби иске, шундый карт.
1) туры килә 2) туры килми
А5. Әнисе бик борчылды..
1) туры килә 2) туры килми
А6. Әнисе дусларына шалтыратырга кушты.
1) туры килә 2) туры килми
А7. Алар туган көнне уздырырга булдылар..
1) туры килә 2) туры килми
А8. Фәридәгә бик күңелсез булды.
1) туры килә 2) туры килми

**4.Туган көнгә чакыру язу.**
**5.Фәридәгә котлау открыткасы язарга кирәк.**
Һәр төркемгә конверт бирелә. Укучылар сүзләрдән котлау җыялар.

**6. Бүләк әзерләү. Туган көнгә нәрсәләр бүләк итеп була? Укытучы**: Әйе, укучылар, чәчәк бәйләмен бөтен кешеләргә дә бүләк итәргә мөмкин, ләкин нинди чәчәк бүләк итәргә икәнлеген белергә кирәк. Чәчәкләрнең дә бит үз телләре бар икән... (**20 нче слайд:** чәчәкләр белән танышу).

-Укучылар, ә сез рәсем ясарга яратасызмы? Әйдәгез, хәзер чәчәк рәсеме ясыйбыз. *(Укучылар ясаган чәчәк рәсемнәрен кисеп алып, алдан ясаган кәрзингә җилем ярдәмендә беркетәләр һәм шулай ук алдан әзерләнгән рамкага куеп, Фәридәгә бүләк итәләргә җыеналар). (Бүләкне янга куеп тору).*
–Бүләк булды.
– Әйдәгез, Фәридәгә табын әзерләргә булышыйк.

*Слайдта ризыклар күрсәтелә, укучылар исемен әйтергә тиеш.*

- Без әзерлибез табын,

Китереп бөтен ягын.
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына — чәкчәк.
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.

- Укучылар, табынга тагын нәрсә җитми?
- Җиләк- җимешләр.
- Әйдәгез табынга җиләк-җимешләр куйыйк.

**7. “Табышмак әйтәм -уйлап тап” уенын уйныйбыз.**

1. Үзе кып-кызыл, күлмәге ямь-яшел.

- Карбыз.

*Слайдта җиләк-җимешләр рәсеме чыгып бара.*

2. Сап-сары – кояш түгел,
Эчләре бүлем-бүлем.
Кабыгын әрчеп алдык,
Өләштек телем-телем.

- Әфлисун.

3. Алма дисәң дә алалар,
Нәрсә соң ул, балалар?

- Алма.

- Табыныбыз әзер.

**8. “Винни пух” мультфильмыннан өзек карау.**

- Винни пух үзен табын янында дөрес тотамы?
- Юк.
- Укучылар, ә сез ашаганда үзеңне тоту кагыйдәләрен беләсезме? Р. Фәхреддин үзенең “Балаларга үгет һәм нәсыйхәт” китабында болай ди:

1. Ашарга утырган вакытта иң элек кулларыгызны юыгыз һәм яхшылап сөртегез.
2. Үзегездән олы кешеләр булганда, алардан алда утырмагыз!
3. Зур-зур алмагыз, ашыкмагыз. Яхшы чәйнәгез, кул вә киемнәрегезне буямагыз, табактан үзегез өчен бернәрсә дә сайламагыз, башкаларның ашавына карап тормагыз, комсыз булмагыз, күп ашарга гадәтләнмәгез.
4. Авыз тутырып капмагыз, кашыгыгызны савытның һәр тарафында йөртмәгез.
5. Ашаганнан соң кулларыгызны, авызыгызны су вә сабын белән яхшы юыгыз, тастымал белән сөртегез.

Табын янында үзеңне ничек тотарга кирәк? *( инф.+ярамый структуралы җөмләләр төзү аша, кагыйдәләрне кабатлау.)*

- Табын янында сөйләшергә ярамый;
- Авызны чапылдатырга ярамый;
- Тизашарга ярамый;
- Алдан ашый башларга ярамый;
- Ризыкны сайланып утырырга ярамый.

**V. Рефлексия.** (*дәрескә йомгак ясау*).

- Укучылар, без бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек?

-Нинди хикәя белән таныштык?

-Фәридә сезгә ошадымы?

-Фәридәгә нинди киңәшләр бирдегез?

-Дәрестә тагын нәрсә үзләштердегез?

-Туган көнгә баргач, үзеңне ничек тотарга кирәк?һ.б.

- Сезгә әсәр ошадымы?

- Фәридә дөрес эшләгәнме?

- Әбиләребез турында шулай әйтергә ярыймы?

- Автор бу әсәре белән нәрсә әйтергә тели?

**Укытучы: Әбием! Дәү әнием! Нинди матур сүз бу! Бу сүз әни сүзе кебек үк якын һәм кадерле. Әбиләрне хөрмәт итәргә һәм яратырга кирәк. Әбиләребез сезне тәрбияләүгә күпме көч куялар. Матур җырлары, әкиятләре аша күңелләргә рухи байлык иңдерәләр. Шуңа күрә аларны беркайчан да рәнҗетмәгез, авыр сүзләр әйтеп йөрәкләрен телгәләмәгез! Аларны яратыгыз, хөрмәт итегез!**

**VI.Өй эше бирү.**

Ясаган бүләгебезне Фәридәгә бүләк итү өчен , туган көн бәйрәме булсын өчен, Фәридә нинди булырга тиеш? Хикәяне үзгәртеп язгыз.


**6.Билгеләр кую.**

**Үзбәя**

- Укучылар,сезгә дәрес ошадымы? Бүгенге дәресне “5” билгесенә кемнәр үзләштерде? Кемнәр үз эшчәнлегенә “4”,ә кемнәр “3” билгесе куя? Өстәлегездә билгеләр язылган смайликлар бар. Җөмләләрне укып, түгәрәкләрне күтәрегез.

Дәрес материалын бик әйбәт үзләштердем, хәтта иптәшләремә дә булыша алам:  5

Әйбәт эшлим, материалны аңладым:  4

Әйбәт эшлим, ләкин иптәшемнең ярдәменә каршы килмим:  3